**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2024 елның 19 июлендәге 3041 номерлы карары**

**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2021 елның 17 августындагы 2038 номерлы**
**«Казан шәһәре Идел буе районының Тихорецк урамындагы**
**җир кишәрлекләре өлешләренә ачык сервитут билгеләү турында»гы**
**карарын гамәлдән чыккан дип тану хакында**

Россия Федерациясе Җир кодексының 48 статьясы, 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы федераль закон, «Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы каршындагы Татарстанның юл-транспорт комплексын карап тоту һәм үстерү буенча баш идарәсе» дәүләт казна учреждениесе гаризасы нигезендә **карар бирәм**:

1. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2021 елның 17 августындагы 2038 номерлы «Казан шәһәре Идел буе районының Тихорецк урамындагы җир кишәрлекләре өлешләренә ачык сервитут билгеләү турында»гы карарын гамәлдән чыккан дип танырга.

2. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карар «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) рәсми басылып чыкканнан соң гамәлгә керә дип билгеләргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары Р.Р.Шәфигуллинга йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**